Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Олы Әшнәк авыл җирлеге Советы

**КАРАР № 9**

Олы Әшнәк авылы                                        2019 елның 14 июне

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлегенең үзидарәлек милке турында мәгълүматны ачу хакындагы Нигезләмәне раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 елның 16 маендагы “Татарстан Республикасы милке турында мәгълүматны ачу хакындагы нигезләмәне раслау турында” 327 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы территориясендә инвестиция активлыгын күтәрү, шулай ук үзидарәлек милкен нәтиҗәлерәк һәм рациональ файдалану максатларында Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлегенең үзидарәлек милке турында мәгълүматны ачу хакында кушымта итеп бирелә торган Нигезләмәне расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлегенең Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Олы Әшнәк авылы, Г.Тукай урамы, 28А йорт; Кече Әшнәк авылы, Красноармейская урамы, 32А йорт адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Олы Әшнәк авыл җирлеге башлыгы                    Р.А.Хөснетдинова

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Олы Әшнәк авыл җирлеге Советының
2019 елның 14 июнендәге
9 номерлы карары белән
расланды

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлегенең
үзидарәлек милке турында мәгълүматны ачу хакында
НИГЕЗЛӘМӘ

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлегенең үзидарәлек милке турында мәгълүматны ачу хакында нигезләмә 2006 елның 27 июлендәге “Мәгълүмат, мәгълүмат технологияләре турында һәм мәгълүматны яклау хакында” 149-ФЗ номерлы, 2001 елның 21 декабрендәге “Дәүләт һәм үзидарәлек мөлкәтен хосусыйлаштыру турында” 178-ФЗ номерлы, 1993 елның 21 июлендәге “Дәүләт сере турында» 5485-1 номерлы Федераль законнар, 2005 елның 8 апрелендәге “Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте турында” 65-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы нигезендә эшләнде һәм Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлегенең муниципаль милке турында мәгълүмат составын, шулай ук аны, шул исәптән аерым милек объектлары буенча ачу ысулларын, тәртибен һәм срокларын билгели.

1.2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлегенең үзидарәлек милке турындагы мәгълүматны ачу дигәннән барлык кызыксынучы затларның да аңа керү мөмкинлеген тәэмин итү аңлашыла.

1.3. Татарстан Республикасы муниципаль районының муниципаль милекне исәпкә алу объектлары турында мәгълүмат Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Олы Әшнәк авыл җирлеге башлыгы тарафыннан бирелә. Мәгълүмат бирүне кире кагу соратыла торган мәгълүматта дәүләт серен тәшкил итүче мәгълүматлар булган очракта мөмкин.

1.4. Мәгълүматны юридик затлар мәнфәгатьләренә зыян салырлык итеп куллану Россия Федерациясенең гамәлдәге законнарында каралган җаваплылыкка китерә.

1.5. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлегенең муниципаль милке турында мәгълүмат Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлегенең муниципаль милке реестрында теркәлгән мәгълүматлары, шулай ук Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлеге милкендәге җир кишәрлекләре турында мәгълүматлар күләмендә бирелә.

1.6. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлегенең муниципаль милке турында мәгълүматны ачу мәгълүмат тарату һәм кызыксынган затларга мәгълүмат бирү рәвешендә гамәлгә ашырыла.

Мәгълүматны тарату гаммәви мәгълүмат чараларында бастырып чыгару һәм "Интернет"челтәрендәге сайтка урнаштыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

Мәгълүмат кызыксынучы затларның язмача мөрәҗәгатьләре буенча, шул исәптән аерым милек объектлары буенча да гамәлгә ашырыла.

2. Мәгълүматны тарату

2.1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Урахчы авыл җирлегенең аны "Интернет" челтәрендәге сайтта урнаштыру ярдәмендә таратыла торган муниципаль милке турында мәгълүмат түбәндәге мәгълүматлар исемлеге белән билгеләнә (мондый мәгълүматларда керү мөмкинлеге законнар белән чикләнгән мәгълүмат булган очраклардан тыш):

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлеге муниципаль учреждениеләре исемлеге (атамасы, урыны );

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлегенең муниципаль унитар предприятиеләре исемлеге (атамасы, урыны);

устав капиталы өлешләре (акцияләр пакетлары) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлеге милкендә булган хуҗалык җәмгыятьләре исемлеге (хуҗалык җәмгыяте атамасы, урнашу урыны, устав капиталында үзидарәлек өлеше);

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлеге милкендәге күчемсез мөлкәт (биналар, каралтылар) исемлеге (исеме, урнашу урыны, мәйданы, максатчан билгеләнеше, файдалануны чикләү, өченче затларның хокуклары белән йөкләнү);

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлегенең муниципаль милкен хосусыйлаштыруның фараз планы (программасы );

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлеге муниципаль милкен хосусыйлаштыруның фараз планының (программасының) үтәлеше турында хисап.

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлегенең муниципаль милке турында күрсәтелгән мәгълүмат шулай ук гаммәви мәгълүмат чараларында бастырылып чыгарылырга мөмкин.

2.2. Әлеге Нигезләмәнең 2.1 пунктында күрсәтелгән мәгълүматлар финанс елы тәмамланганнан соң дүрт айдан да соңга калмыйча 1 гыйнварга булган торышы буенча Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтында ел саен игълан ителергә тиеш.

2.3. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлегенең муниципаль милкендәге мөлкәт объектлары турында мәгълүматны хосусыйлаштыруга бәйле рәвештә ачып салу хосусыйлаштыру турындагы законнарда билгеләнгән күләмдә гамәлгә ашырыла.

## 3. Кызыксынган затларга мәгълүмат бирү

3.1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлегенең муниципаль милек реестрында теркәлгән аерым мөлкәт объектлары (алга таба - исәпкә алу объектлары) буенча мәгълүмат кызыксынучы затлар мөрәҗәгате буенча Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлегенең муниципаль милек реестрыннан хат яки өземтә рәвешендә бирелә.

3.2. Исәпкә алу объектлары турында мәгълүмат (яисә аны бирүне кире кагу турында дәлилләнгән карар) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлеге башлыгы тарафыннан мөрәҗәгать теркәлгән көннән алып 30 көннән дә соңга калмыйча бирелә.

3.3. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлегенең муниципаль милек реестрыннан өземтәләр бирелә:

исәпкә алу объектларына хокукый ия булучыларга яисә аларның законлы вәкилләренә;

исәпкә алу объектына хокукый ия булучыдан яисә аның законлы вәкиленнән ышанычнамә алган физик һәм юридик затларга;

Россия Федерациясе Хисап палатасына, Татарстан Республикасы Хисап палатасына, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Контроль-хисап палатасына;

җирле үзидарә органнарына һәм Татарстан Республикасы, Россия Федерациясенең башка субъектлары дәүләт хакимияте органнарына;

дәүләт хакимиятенең федераль органнарына, шул исәптән:

күчемсез мөлкәткә хокукларны һәм аның белән килешүләрне дәүләт теркәвенә алучы органнарга,

салым органнарына,

исәпкә алу һәм (яисә) аларның хокукый ияләре белән бәйле эшләр производстволарында булган суд, хокук саклау органнарына, суд пристав-башкаручыларына,

федераль монополиягә каршы органга һәм аның Татарстан Республикасындагы территориаль органына.

3.4. Әлеге Нигезләмәнең 3.3 пунктында күрсәтелмәгән кызыксынучы затларга бары тик Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлегенең муниципаль милек реестрында исәпкә алу объектларының булуы турында мәгълүмат кына бирелә.

3.5. Язма рәвештә бирелә торган соратылган мәгълүматны бирүне кире кагу дәлилләнгән булырга тиеш.

Соратылган мәгълүматны бирүне кире кагу өчен түбәндәге сәбәпләр нигез була:

мөрәҗәгатьтә керү мөмкинлеге законнар белән чикләнгән мәгълүматны үз эченә алган мәгълүматлар соратыла;

мәгълүматы әлеге затны кызыксындырган объектны берсүзсез тәңгәлләштерергә мөрәҗәгатьнең эчтәлеге мөмкинлек бирми;

мөрәҗәгатьтә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлегенең муниципаль милек реестрында мәгълүматлар булмаган мөлкәт объекты күрсәтелгән.